АССОЦИАЦИЯ
«СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНЫХ
ОБРАЗОВАНИЙ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН»

«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКЛӘРЕ
СОВЕТЫ»
АССОЦИАЦИЯСЕ

РЕШЕНИЕ ПРЕЗИДИУМА

ПРЕЗИДИУМ КАРАРЫ

от 12.03.2021

№ ПР-8-3

г. Казань

Җирлекләрнең территориаль планлаштыру һәм шәһәр төзелеше зоналашуы документларын әзерләү һәм күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрына Татарстан Республикасы торак пунктлары чикләре турында белешмәләр керту буенча эшләрнең барышы турында

Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы һәм Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының территориаль планлаштыру һәм шәһәр төзелеше зоналаштыру документларын әзерләү һәм Татарстан Республикасының торак пунктлары чикләре турындагы мәгълүматларны күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрына керту турындагы мәгълүматын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң, «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы» Ассоциациясе Президиумы **карар кылды**:

1. Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы һәм Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турындагы мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына тәкъдим итәргә:

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 19, 23 һәм 30 статьялары нигезендә торак пунктларның һәм территориаль зоналарның чикләре турында белешмәләрне 2023 елның 1 июненә кадәр әзерләүне, шулай ук күрсәтелгән белешмәләрне 2024 елның 1 гыйнварыннан да соңга калмыйча күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрына кертүне тәэмин итәргә;

билгеләнгән выкытта һәм расланган формалар нигезендә Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына, Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына, «Татарстан Республикасының пространство белешмәләре фонды» дәүләт бюджет оешмасына генераль планнар, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектларын эшләү өчен кирәкле булган башлангыч мәгълүматны, шулай ук территориаль планлаштыру һәм шәһәр төзелешен зоналаштыру документларын эшләү барышы турында мәгълүмат бирергә;

генераль планнар проектларын һәм җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектларын эшләгәндә Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы тарафыннан эшләнгән типик техник биремнәрне кулланырга;

муниципаль районның вәкиллекле органы территориаль планлаштыру документларын раслау вәкаләтләрен беркетүче муниципаль берәмлекләр уставларына үзгәрешләр кертүне тәмамларга;

«Татарстан Республикасының пространство белешмәләре фонды» дәүләт бюджет оешмасы белән территориаль планлаштыру документларын актуальләштерү буенча эшләрне башкаруга техник биремнәрне һәм контрактларны килештерергә, башкарылган эшләрне кабул итүдә фондның катнашуын тәэмин итәргә;

территориаль планлаштыру документларын эшләүгә финанс чараларын җәлеп итү максатларында әлеге документларны актуальләштерү белән кызыксынучы инвесторларны һәм җирдән файдаланучыларны җәлеп итәргә;

территориаль планлаштыру һәм шәһәр төзелешен зоналаштыру документларын әзерләү һәм раслау буенча эш барышын профильле министрлыкларда караганда башкарма комитет җитәкчеләренең шәхси катнашуын тәэмин итәргә;

территориаль планлаштыру буенча эш өчен җаваплы затларның квалификациясен күтәрү, аларның эшчәнлеген Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белән координацияләүне тәэмин итү буенча чаралар күрергә.

Вакыты: даими рәвештә

3. Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына, Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары җитәкчеләре

катнашында, территориаль планлаштыру һәм шәһәр төзелешен зоналаштыру документларын закон таләпләренә туры китерү буенча эшләрнең барышын җентекләп карап, эшче төркемнәр утырышлары графигын расларга һәм уздыруны оештырырга тәкъдим итәргә.

Вакыты: 2021 елның 1 маена кадәр

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту Советның башкарма сәркатибе А.Г. Барышевка йөкләнә.

Рәисе **Ә.С.Гобәйдуллин**